РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_22_» _август______ 2024 ел №_260__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә» 2013 елның 26 ноябрендәге 192 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге № 384-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2013 елның 26 ноябрендәге 192 номерлы карарына (Чирмешән муниципаль районы Советының 2014 елның 20 октябрендәге 235 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 249 номерлы, 2022 елның 09 июнендәге 121 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяда:

- 4 пунктның 6 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (алга таба - бюджет акчаларының баш администраторлары) тарафыннан эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;».

- 9 пунктның 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын юкка чыгару өчен аның карамагына бүлеп

бирелгән ассигнованиеләрдән файдалануның адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә, моңа бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләре керми;».

- 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә: «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында федераль бюджет акчалары капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш)».

1.2. 13 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә «Җирле бюджет кытлыгын эчке финанслау чыганаклары составына түбәндәгеләр керә:

- номиналь бәясе Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырудан кергән акчалар белән аларны юкка чыгаруга юнәлдерелгән акчалар арасындагы аерма;

- Россия Федерациясе валютасында кредит оешмаларының район тарафыннан җәлеп ителгән һәм түләнгән кредитлары арасындагы аерма;

- Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетлары тарафыннан җирле бюджетка бирелгән Россия Федерациясе валютасында Район тарафыннан җәлеп ителгән һәм юкка чыгарылган бюджет кредитлары арасындагы аерма;

- тиешле финанс елы дәвамында Район бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү;

- Район бюджеты кытлыгын эчке финанслауның башка чыганаклары.

Район бюджеты кытлыгын эчке финанслауның башка чыганаклары составына түбәндәгеләр керә:

- муниципаль Район милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның башка рәвешләрен сатудан кергән акчалар;

- Район бюджеты акчалары буенча курс аермасы;

- муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокукларын гарантка биреп тору белән бәйле булган очракта, Район гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме;

- районның башка бурыч йөкләмәләрен түләүгә Россия Федерациясе валютасында юнәлдерелә торган акчалар күләме;

- Район бюджетыннан юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар һәм Район бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма;

- Район бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар һәм җирле бюджеттан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма;

- Район бюджетының бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр үткәргәндә Район бюджетының бердәм счетыннан күчерелгән акчалар белән Район бюджетының бердәм счетына күчерелгән акчалар арасындагы аерма.

Агымдагы финанс елы башына Район бюджеты акчаларының калган өлешләре:

- муниципаль юл фондының хисап финанс елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә, шулай ук район Советы карары белән билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында кассадагы вакытлыча өзеклекләрне каплауга һәм хисап финанс елында әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле Район исеменнән товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактларны түләүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга, күрсәтелгән максатларга файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә күрсәтелгән субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә хисап финанс елында бирелүе гамәлгә ашырылган юридик затларга субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга, район Советының җирле бюджет турындагы карарында каралган очракларда;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә муниципаль берәмлекнең бурыч тотрыклылыгы уртача яисә түбән дәрәҗәдәге заемчылар төркеменә кертелгән заем алучыларның гомуми суммасының Район бюджеты кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы йомгаклары буенча районның бурыч йөкләмәләрен каплау күләмнәреннән артып китү күләмендә агымдагы финанс елында районның бурыч йөкләмәләрен кыскартучы түләүләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының икътисадый сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов